| СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 елның 07 ноябре** Бишнә ав. **№ 12**

Зеленодольск муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге №131 – ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлегендә рөхсәтсез калдыклар ташлау урыннарын бетерү.

2. Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**